| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2024 Олы Кайбыч ав. № 387

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары булып торучы һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре булган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 26 июнендәге 401 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары булып торучы һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре булган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 26 июнендәге 401 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның «б» пунктчасында:

- 6 абзацта «бирү» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләгән көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлекле яңа җиденче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә әзерләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычын түләтү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгели;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров